СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ГОРОД АГРЫЗ» АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«ӘГЕРҖЕ ШӘҺӘРЕ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
СОВЕТЫ

**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**

24.04.2020 Әгерҗе ш. № 41-1

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының "Әгерҗе шәһәре" муниципаль берәмлеге Советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының "Әгерҗе шәһәре" муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

"Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы "Әгерҗе шәһәре" муниципаль берәмлегенең төзелеш һәм җирдән файдалану кагыйдәләренә" 2020 елның 05 февралендәге 02-08-01/90 номерлы Татарстан Республикасы Әгерҗе районы прокуратурасының Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, Россия Федерациясе Җир кодексы, "Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, "Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" 2019 елның 29 декабрендәге 472-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә протестын карап, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР ИТТЕ,

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының "Әгерҗе шәһәре" муниципаль берәмлеге Советының 2018 елның 23 мартындагы 21-3 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль

районының “Әгерҗе шәһәре” муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертергә, кушымтада бирелгән редакциядә бәян итеп:

- Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре (1 нче Том. Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен куллану тәртибе. Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү тәртибе);

- Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре (2 нче Том. Шәһәр төзелешен зоналаштыру карталары. Шәһәр төзелеше регламентлары);

- Шәһәр төзелешен зоналаштыру картасы (Территориаль зоналар);

- Шәһәр төзелешен зоналаштыру картасы (Ябылу чикләре).

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлегенең мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (http://agryz.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлеге Советының төзелеш, торак-коммуналь хуҗалык, транспорт һәм элемтә буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет рәисе В.В. МАКАРОВ